**Исполнительный комитет Поручиковского сельского поселения Заинского муниципального района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге башкарма комитеты**

ул. Новая, д.13 с. Поручиково,
Заинский район, 423520

Яңа урамы, 13 нче йорт, Поручик авылы,
Зәй районы, 423520

Телефон, факс 3-70-49. Электронный адрес: Por.Zai@tatar.ru, сайт: www. http://zainsk.tatarstan.ru/poruchikovskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**29.07.2019** **№36**

**«Сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында»**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2019 нчы елның 10 нчы июлендәге 67/516 номерлы «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» карары, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә

**карар бирә:**

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге сайлау участоклары территориясендә махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазландырырга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең сайлау участоклары территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен урыннар исемлеген расларга (Кушымта).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.
4. Әлеге карарны Зәй муниципаль районы сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә Поручик авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **П.С. Уразайкин**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Поручик авыл җирлеге Башкарма
комитет карарына
Кушымта
29.07.2019 № 36

**Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең сайлау участоклары территориясендә урыннар исемлеге**

| № п/п | Сайлау участогы № | Объектның исеме һәм урнашу адресы |
|---|---|---|
| 1. | 1484 | Мәгълүмат стенды<br>Поручик авылы, Горбунова ур., 2 «а» йорт |
| 2. | 1485 | Мәгълүмат стенды<br>Сәрәпәле авылы, Үзәк ур.,28 йорт |